| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет<br>Каенлинского сельского поселения<br>Нижнекамского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Түбән Кама муниципаль районы<br>Каенлы авыл җирлеге<br>Советы |
| --- | --- |
| 423560, Нижнекамский район,<br>с. Каенлы,ул. Ленина, 44 | 423560, Түбән Кама районы,<br>Каенлы авылы,Ленин урамы, 44 |

тел./факс (8555) 44-91-26, электронный адрес: Kaenlinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.kaenlinskoe-sp.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

18.12.2020 ел №23

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендә кабул ителгән 8-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру турында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Каенлы авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге сайтын http://kaenlinskoe-sp.ru Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайт итеп билгеләргә.

2. Кушымта итеп бирелгәннәрне раславга:

- Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучыга аның соравы буенча мәгълүмат бирү тәртибе (1 нче кушымта);

- Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеген раслау тәртибе (2 нче кушымта);

- Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында Интернет челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеге (3 нче кушымта);

- Интернет челтәрендәге рәсми сайттан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына карата таләпләр (4 нче кушымта).

3. Түбән Кама муниципаль районы Каенлыавыл җирлеге Советының 2015 елның 11 мартындагы 2 номерлы «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру турында» карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

Җирлек башлыгы Р.Р. Гарипов

Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге Советының
2020 елның 18 декабрендәге
23 номерлы карарына
1 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Каенлыавыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучыга аның соравы буенча мәгълүмат бирү тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

Түбән Кама муниципаль районы Каенлыавыл җирлеге җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучыга аның соравы буенча мәгълүмат бирүнең әлеге тәртибе (алга таба - Тәртип) 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» (алга таба – 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон) Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге 860 номерлы «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат биргән өчен түләү алу кагыйдәләрен раслау турында» (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге 860 номерлы карары) карары нигезендә эшләнгән һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучыга аның соравы буенча мәгълүмат бирү процедурасын билгели.

2. Мәгълүматтан файдаланучыга аның соравы буенча мәгълүмат бирү тәртибе

2.1. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат телдән һәм документлаштырылган мәгълүмат рәвешендә, шул исәптән электрон документ рәвешендә дә бирелергә мөмкин.

2.2. Язма рәвештә төзелгән сорату җирле үзидарә органына кергән көннән өч көн эчендә теркәлергә тиеш. Телдән төзелгән сорату, керү датасы һәм вакыты күрсәтелеп, аның керү көнендә теркәлергә тиеш.

2.3. Сорату, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, аны теркәгән көннән утыз көн эчендә каралырга тиеш. Соратып алына торган мәгълүматны күрсәтелгән срокта бирү мөмкин булмаса, мәгълүматтан файдаланучыга, соратуны теркәгәннән соң җиде көн эчендә, соратып алына торган мәгълүматны бирү сәбәбен һәм вакытын күрсәтеп, сорату өчен әлеге Тәртиптә билгеләнгән сроктан унбиш көннән дә артмый торган вакыт эчендә, соратуга җавапны кичектереп тору турында хәбәр ителә.

2.4. Сорату буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат, соратып алына торган мәгълүмат булган яисә аңа теркәлә торган соратуга җавап рәвешендә, яисә 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законның 20

статьясы нигезендә, әлеге мәгълүматны бирүдән нигезле баш тарту рәвешендә бирелә. Соратуга җавапта җирле үзидарә органының исеме, почта адресы, җавапка кул куйган затның вазыйфасы, шулай ук соратуга җавап реквизитлары (теркәү номеры һәм датасы) күрсәтелә.

2.5. Мәгълүмат соратып алына торган мәгълүмат күләменең һәм форматына бәйле рәвештә, шул исәптән соратып алына торган документларның һәм (яки) материалларның күчермәләрен ясау һәм җибәрү чыгымнарын исәпкә алып, мондый мәгълүматны бирү тәртибен регламентлаучы законнар нигезендә, түләүсез яисә түләүле нигездә бирелә. Мәгълүматның түләүле булуы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге 860 номерлы карары нигезендә билгеләнә.

2.6. Закон нигезендә мәгълүмат биргән өчен түләү алынмаса, җирле үзидарә органы мәгълүматтан файдаланучыга әлеге Тәртипнең 2.3 - 2.4 пунктларында каралган тәртиптә сорату нигезендә мәгълүмат бирә.

2.7. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге 860 номерлы карары нигезендә сорату буенча мәгълүмат биргән өчен түләү алу күздә тотылган очракта, җирле үзидарә органы бу хакта сорату җибәргән мәгълүматтан файдаланучыга билгеләнгән тәртиптә алынган соратуны теркәгәннән соң 7 эш көне эчендә хәбәр итә.

Түләүле нигездә бирелә торган җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүмат мәгълүматтан файдаланучыга күрсәтелгән мәгълүматны биргән өчен түләгәннән соң җибәрелә (тапшырыла).

2.8. Мәгълүматтан файдаланучы аны кәгазьдә яки компьютер тупланмасында турыдан-туры җирле үзидарә органында алырга тели икән, җирле үзидарә органы, соратуга җавап итеп, мәгълүматтан файдаланучыга соратып алына торган мәгълүматны алырга мөмкин булган вазыйфаи зат турында, адресын, телефонын, эш режимын һәм кабул итүнең төгәл датасын күрсәтеп, өстәмә мәгълүмат бирә.

2.9. Төгәл булмаган мәгълүматлар биргән җирле үзидарә органы мәгълүматтан файдаланучының язмача гаризасы буенча бушлай, дәлилләп, булган төгәлсезлекләрне бетерергә тиеш.

2.10. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат түбәндәге очракта бирелми:

1) соратуның эчтәлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында соратып алына торган мәгълүматны билгеләргә мөмкинлек бирми;

2) соратуда соратуга җавап җибәрү өчен почта адресы, электрон почта адресы яки факс номеры яисә сорату җибәргән мәгълүматтан файдаланучы белән элемтәгә керергә мөмкин булган телефон номеры күрсәтелмәгән;

3) соратып алына торган мәгълүмат сорату кергән җирле үзидарә органы эшчәнлегенә керми;

4) соратып алына торган мәгълүмат керү мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматка керә;

5) соратып алына торган мәгълүмат мәгълүматтан файдаланучыга элек бирелгән;

6) соратуда дәүләт органы, җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителгән актларны хокукый бәяләү мәсьәләсе, дәүләт органы, аның территориаль органнары, җирле үзидарә органы яисә ведомство буйсынуындагы оешмалар эшчәнлегенә

анализ ясау яисә сорату җибәргән мәгълүматтан файдаланучының хокукларын яклауга турыдан-туры бәйле булмаган бүтән аналитик эш башкару мәсьәләсе куела.

Җирле үзидарә органы, әгәр бу мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан яки «Интернет» челтәрендә урнаштырылган булса, үз эшчәнлеге турында сорату буенча мәгълүмат бирмәскә хокуклы. Бу очракта җирле үзидарә органы соратуга җавапта соратып алына торган мәгълүмат басылып чыккан массакүләм мәгълүмат чараларының исемен, чыгу датасын һәм номерын һәм (яки) соратып алына торган мәгълүмат урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресын күрсәтү белән чикләнә.

2.11. Әгәр сорату җибәрелгән җирле үзидарә органы эшчәнлегенә керми икән, соратуны теркәгәннән соң җиде кон эчендә ул соратып алына торган мәгълүматны бирү вәкаләтләре бирелгән дәүләт органына яисә җирле үзидарә органына җибәрелә. Соратуның адресын үзгәртү турында шул ук срокта сорату җибәргән мәгълүматтан файдаланучыга хәбәр ителә. Әгәр җирле үзидарә органында соратып алына торган мәгълүматның башка дәүләт органында, җирле үзидарә органында булуы турында мәгълүмат булмаса, бу хакта соратуны теркәгәннән соң җиде көн эчендә сорату җибәргән мәгълүматтан файдаланучыга хәбәр ителә.

2.12. Соратып алына торган мәгълүмат керү мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматка керсә, соратуга җавапта аның нигезендә әлеге мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге чикләнгән актның төре, исеме, номеры һәм кабул итү датасы күрсәтелә. Соратып алына торган мәгълүматның бер өлеше керү момкинлеге чикләнгән мәгълүматка керсә, ә калган мәгълүматка һәркемгә керү мөмкин булса, җирле үзидарә органы, керү мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматтан тыш, соратып алына торган мәгълүматны бирергә тиеш.

Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге Советының
2020 елның 18 декабрендәге
23 номерлы карарына
2 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеген раслау тәртибе

1.Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнашкан җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында исемлекне раслау тәртибе (алга таба - Тәртип) 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» Федераль закон (алга таба - 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә эшләнгән.

2. Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары (алга таба - җирле үзидарә органнары) эшчәнлеге турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган мәгълүмат исемлеге (алга таба - исемлек) Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге Советы карары белән раслана.

Исемлеккә үзгәрешләр кертү аны раслау өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Исемлек җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат составын, мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру вакытын, аны яңарту, мәгълүматтан файдаланучыларның үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үз вакытында гамәлгә ашыруны һәм яклауны тәэмин итә торган срокларын, шулай ук әлеге мәгълүматны урнаштыруга карата башка таләпләрне билгели.

4. 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законда каралган Түбән Кама муниципаль районы Каенлыавыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеккә кертелергә һәм Түбән Кама муниципаль районы Каенлыавылҗирлегенең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге Советының
2020 елның 18 декабрендәге
23 номерлы карарына
3 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында Интернет челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеге

| т/с | Мәгълүмат категориясе | Урнаштыруның кабатланып тору вакыты |
|---|---|---|
| 1 | Җирле үзидарә органы турында гомуми мәгълүмат: | |
| 1.1 | Җирле үзидарә органы атамасы һәм структурасы, почта адресы, электрон почта адресы (булганда), җирле үзидарә органнарының белешмә хезмәтләренең телефон номерлары. | Актуаль хәлдә саклана. |
| 1.2 | Җирле үзидарә органы вәкаләтләре, әлеге органнарның структур бүлекчәләре бурычлары һәм функцияләре турында белешмәләр, шулай ук әлеге вәкаләтләрне, бурычларын һәм функцияләрен билгели торган норматив хокукый актлар исемлеге. | Тиешле норматив-хокукый актлар расланганнан яисә үзгәргәннән соң 5 эш көне эчендә. Норматив-хокукый актлар исемлеге актуаль хәлдә саклана. |
| 1.3 | Ведомство буйсынуындагы оешмалар исемлеге, аларның бурычлары һәм функцияләре турында мәгълүмат, шулай ук почта адреслары, электрон почта адреслары (булганда), ведомство буйсынуындагы оешмаларның белешмә хезмәтләре телефон номерлары. | Актуаль хәлдә саклана. |
| 1.4 | Җирле үзидарә органы, аның структур бүлекчәләре җитәкчеләре, ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре турында белешмәләр (фамилияләре, исемнәре, атасының исеме, шулай ук күрсәтелгән затларның ризалыгы белән алар турында башка белешмәләр). | Актуаль хәлдә саклана. |
| 1.5 | Җирле үзидарә органы, ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагындагы мәгълүмат системалары, мәгълүматлар банкы, | Тиешле мәгълүмат системалары, мәгълүматлар банклары, реестрлар, регистрлар гамәлгә кергәннән соң (яңартылганнан соң) 5 эш көне |

| | | |
|---|---|---|
| | реестрлар, регистрлар исемлеге. | эчендә. |
| 1.6 | Җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә куелган массакүләм мәгълүмат чаралары турында белешмәләр (булганда). | Гамәлгә куйганнан соң 5 эш көне эчендә. |
| 2 | Җирле үзидарә органнарының норма чыгару эшчәнлеге турында мәгълүмат: | |
| 2.1 | Җирле үзидарә органы тарафыннан бастырып чыгарылган муниципаль хокукый актлар, аларга үзгәрешләр кертү, аларның үз көчләрен югалтуын тану, аларның суд тарафыннан гамәлдә булмавын тану турындагы белешмәләрне, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда муниципаль хокукый актларны дәүләт теркәвенә алу турындагы белешмәләрне дә кертеп. | Муниципаль хокукый акт кабул ителгәннән соң, аны суд тарафыннан гамәлдә түгел дип таныганнан соң 5 эш көне эчендә. |
| 2.2 | Җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарына кертелгән муниципаль хокукый актлар проектларының текстлары. | Муниципаль хокукый акт проекты җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарына кертелгәннән соң 5 эш көне эчендә. |
| 2.3 | Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында мәгълүмат. | Мәгълүмат «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, заказларны урнаштыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштырылган. |
| 2.4 | Административ регламентлар, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү стандартлары. | Тиешле административ регламентлар, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү стандартлары расланганнан соң 5 эш көне эчендә. |
| 2.5 | Җирле үзидарә органнары тарафыннан законнар һәм башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә карауга кабул ителә торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм башка документларның билгеләнгән формалары. | Актуаль хәлдә саклана. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6 | Муниципаль хокукый актларга шикаять белдерү тәртибе. | Актуаль хәлдә саклана. |
| 3 | Җирле үзидарә органнарының максатчан һәм башка программаларда, халыкара хезмәттәшлектә катнашуы турында мәгълүмат. | Тиешле максатчан яки башка программада, халыкара хезмәттәшлектә катнашу турында җирле үзидарә органнарынараслау кергән көннән алып 5 эш көне дәвамында |
| 4 | Җирле үзидарә органнары үткәрә торган чаралар турында мәгълүмат, шул исәптән җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең һәм рәсми делегацияләренең рәсми визитлары һәм эш сәфәрләре турында белешмәләр. | Актуаль хәлдә саклана. |
| 5 | Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау торышы һәм аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар, фаразланучы һәм барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр, халыкны алардан саклау алымнары һәм ысуллары турында мәгълүмат, шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә гражданнар һәм оешмаларга җирле үзидарә органы тарафыннан җиткерелергә тиешле башка мәгълүмат. | Актуаль хәлдә саклана. |
| 6 | Җирле үзидарә органнары, ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре, шулай ук җирле үзидарә органнарында, ведомство буйсынуындагы оешмаларда үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре турында мәгълүмат. | Квартал саен |
| 7 | Җирле үзидарә органы җитәкчеләренең һәм урынбасарларының рәсми чыгышлары һәм гаризаларының текстлары. | Рәсми чыгыш ясаганнан яки гаризадан соң 5 эш коне эчендә. |
| 8 | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында статистик мәгълүмат, шул исәптән: | |

| | | |
|---|---|---|
| 8.1 | Җайга салу җирле үзидарә органы вәкаләтләренә кертелгән икътисадый, социаль һәм башка өлкәләрнең торышын һәм үсеш динамикасын характерлаучы статистик мәгълүматлар һәм күрсәткечләр. | Квартал саен |
| 8.2 | Җирле үзидарә органы, ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан бүлеп бирелә торган бюджет акчаларыннан файдалану турында белешмәләр. | Мәгълүмат «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, заказларны урнаштыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштырылган. |
| 8.3 | Оешмаларга һәм шәхси эшмәкәрләргә бирелгән ташламалар, түләү срогын кичектерүләр, ваклап түләү, бюджетка түләүләр буенча бурычларны гамәлдән чыгару турында белешмәләр. | Квартал саен |
| 9 | Җирле үзидарә органын кадрлар белән тәэмин итү турында мәгълүмат, шул исәптән: | |
| 9.1 | Гражданнарның муниципаль хезмәткә керү тәртибе. | Актуаль хәлдә саклана. |
| 9.2 | Җирле үзидарә органнарында булган муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында мәгълүмат. | Актуаль хәлдә саклана. |
| 9.3 | Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатларга квалификация таләпләре. | Тиешле муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән срокларда. |
| 9.4 | Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар шартлары һәм нәтиҗәләре. | Тиешле муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән срокларда. |
| 9.5 | Җирле үзидарә органнарында вакантлы вазыйфаларны биләү мәсьәләсе буенча мәгълүмат алырга мөмкин булган телефон номерлары. | Конкурс үткәрү турында хәбәрнамә нигезендә. |
| 9.6 | Җирле үзидарә органына караган белем бирү учреждениеләре исемлеге, мәгариф учреждениеләренең почта адресларын, шулай ук әлеге белем бирү учреждениеләре турында белешмә характердагы мәгълүмат | Актуаль хәлдә саклана. |

| | | |
|---|---|---|
| | алырга мөмкин булган телефон номерларын күрсәтеп. | |
| 10 | Җирле үзидарә органнарының гражданнар (физик затлар), оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары мөрәҗәгатьләре белән эшләве турында мәгълүмат, шул исәптән: | |
| 10.1 | Гражданнарны (физик затларны), шул исәптән оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен кабул итү тәртибе һәм вакыты,бу эшчәнлекне җайга сала торган актларны күрсәтеп, аларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе | Актуаль хәлдә саклана.<br>Эшчәнлекне җайга сала торган актлар муниципаль хокукый акт кабул ителгәннән соң 5 эш көне эчендә урнаштырыла. |
| 10.2 | Әлеге исемлекнең 9.1 пунктында күрсәтелгән затларны кабул итүне оештыру, аларның мөрәҗәгатьләрен карауны тәэмин итү вәкаләтләренә караганбүлекчә җитәкчесенең яисә башка вазыйфаи затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, шулай ук белешмә характердагы мәгълүматны алырга мөмкин булган телефон номеры. | Актуаль хәлдә саклана. |
| 10.3 | Әлеге исемлекнең 9.1 пунктында күрсәтелгән затларның мөрәҗәгатьләренә күзәтү, шулай ук әлеге мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре һәм кабул ителгән чаралар турында гомумиләштерелгән мәгълүмат. | Квартал саен |
| 11 | Җирле үзидарә органнары каршында оешкан учреждениеләр һәм оешмаларның рәсми сайтларына сылтамалар (булганда). | Актуаль хәлдә саклана. |

Искәрмә:

Әлеге исемлектә каралган норматив хокукый һәм башка актлар Интернет челтәрендәге рәсми сайтта, актны кабул иткән җирле үзидарә органының исемен, аның төрен, актның исемен, аны кабул итү (кул кую) датасын һәм номерын, шулай ук, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда,муниципаль хокукый актны дәүләт теркәве турында белешмәне күрсәтеп урнаштырыла.

Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге Советының
2020 елның 18 декабрендәге
23 номерлы карарына
4 нче кушымта

Интернет челтәрендәге рәсми сайттан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына карата таләпләр

1. Интернет челтәрендәге рәсми сайттан (алга таба - сайт) файдалануны тәэмин итүнең технологик һәм программа чаралары кулланучыларның сайттагы мәгълүмат белән танышу өчен файдаланаалуынһәркем керә алырлык программа белән тәэмин ителеш нигезендә тәэмин итәргә тиеш.

2. Сайтны карау өчен,кулланучылар компьютерында бу максатка махсус булдырылган технологик һәм программа чараларын урнаштыру каралмаска тиеш.

3.Кулланучыга сайт структурасы турында күрсәтмә мәгълүмат бирелергә тиеш.

4. Сайтныалып баруның технологик һәм программа чаралары тәэмин итәргә тиеш:

а) сайтны алып баруның технологик чаралары һәм программа белән тәэмин ителеше ярдәмендә башкарылган операцияләрне исәпкә алуның электрон журналларын алып бару;

б) мәгълүматны әлеге чыганактан торгызу мөмкинлеген тәэмин итә торган резерв чыганагына көн саен күчереп алу;

в) мәгълүматны юк итүдән, модификацияләүдән һәм аңа керүне блоклаудан, шулай ук мондый мәгълүматка карата хокуксыз башка гамәлләрдән яклау;

г) сайтта урнаштырылган мәгълүматныаны беренчел урнаштырганнан соң 5 ел эчендә саклау.

5. Сайттагы мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырылырга тиеш.

6. Чит ил юридик затларның атамаларын, физик затларның фамилияләрен һәм исемнәрен латин алфавиты хәрефләрен кулланып күрсәтү рөхсәт ителә.